**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ СТАРОКАДЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

Советская ул, 6, с.Старое Кадеево, 423117

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ИСКЕ КАДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Совет урамы, 6, Иске Кади авылы, 423117

тел.(884396) 3-13-25 факс (884396) 3-13-25 email: Skad.Cmn@tatar.ru

**№135** **26.12.2024 ел**

# Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Кади авыл җирлеге Советы КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге Советының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 26 апрелендәге 81 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Кади авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Кади авыл җирлеге Советының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Кади авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 26 апрелендәге 81 номерлы карарына (җирлек Советының 28.08.2018 ел № 92, 15.11.2018 ел № 99, 19.10.2020 ел № 6, 15.11.2022 ел № 72, 31.01.2023 ел №77, 20.06.2024 ел №112 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 өлешнең 3 абзацын бәян итәргә: «Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләме 13990 сум

тәшкил итә»;

1.2. «Айлык акчалата бүләкләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм түләү күләмнәре» 7 нче кушымтада 1 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә: «1. Иске Кади авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә премиядән тыш түләнә, муниципаль хезмәткәрләргә җирле үзидарә органы җитәкчесе карары белән вазыйфаи окладның 41 процентыннан артмаган күләмдә билгеләнә.

1.3. «Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы авыл җирлеге башлыгына айлык акчалата түләү күләмнәре» 3 нче кушымтасын яңа редакциядә кушымтада каралганча бәян итәргә.

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Чирмешән муниципаль районы
Иске Кади авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Н.В.Мөктәсимов

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Иске Кади авыл җирлеге Советының
2024 елның 26 декабрендәге
№ 156 карарына кушымта

Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы
авыл җирлеге башлыгына айлык акчалата түләү күләмнәре

| Вазыйфалар атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
| --- | --- |
| Башлык | 19173 |